МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 79/о

«29» 07 2022

БОЕРЫК

Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аңа төзәтмәләр кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аңа төзәтмәләр кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга (кушымтада бирелә).

2. Юридик бүлеккә (Э.Ю.Латыйповага), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ. Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә

ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 26 октябрендәге 163/о номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

5. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2022 елның 29
июлендәге 79/о номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аңа төзәтмәләр кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аңа төзәтмәләр кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – регламент) Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аңа төзәтмәләр кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызу белән шөгыльләнүче юридик затлар яки шәхси эшкуарлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тора.

Мөрәҗәгать итүче исеменнән юридик зат җитәкчесе яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ышаныч кәгазе яисә үзенең шәхесен таныклаучы документлар нигезендә эш итә.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмәләр кертү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан

күрсәтелә.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) Министрлык боерыгы формасында рәсмиләштерелгән инвестиция программасын раслау турында карар;

2) инвестиция программасын раслаудан баш тарту турында карар;

3) Министрлык боерыгы формасында рәсмиләштерелгән инвестиция программасына төзәтмә кертү турында карар;

4) инвестиция программасына төзәтмә кертүдән баш тарту турында карар;

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Министрлык бланкында рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы (алга таба – Республика порталы) (https://uslugi.tatarstan.ru/) шәхси кабинетына.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яки кәгазь документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәтен кәгазьдә күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәреп яисә шәхсән тапшырылган булса, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гаризаны һәм документларны Министрлыкта теркәгән көннән соң календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көнлек чорда күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталындагы шәхси кабинеты аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә Республика порталындагы шәхси кабинетта күренә торган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы беркетелгән көннән соң календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көнлек чорда күрсәтелә.

2.4.3. Министрлык инвестиция программасын инвестиция программасын гамәлгә ашыра башлаган елга кадәрге елның 30 октябренә кадәрге срокта раслый.

2.4.4. Мөрәҗәгать итүче инвестиция программасына төзәтмәләр проектын (шул исәптән бу елга расланганын да) агымдагы елның 30 августына кадәр

юллый. Министрлык инвестиция программага үзгәреш кертү проекты раслауга җибәрелгән елның 20 ноябренә кадәр инвестиция программасын үзгәртү проектын раслый.

Салкын су белән тәэмин итү һәм (яисә) ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системаларына тоташтыру (технологик ялгау) чаралары белән бәйле инвестиция программасын (шул исәптән агымдагы елга расланган) үзгәртү һәм аңа тиешле үзгәрешләр кертү турында гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан ел дәвамында җибәрелергә мөмкин.

2.4.5. Концессия килешүе төзегән оешманың инвестиция программасы концессия килешүе үз көченә кергән көннән алып беренче елда Министрлык тарафыннан инвестиция программасы проекты раслау өчен җибәрелгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча раслана.

2.4.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән, шул исәптән электрон документ формасында да, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергәннән соң ике календарь көне дәвамында җибәрелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Министрлыкның рәсми сайтында һәм Республика порталында урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Министрлыкның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлык вазыйфаи затының, дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) инвестиция программасын раслау турында гариза (әлеге регламентка 1 нче кушымта) яисә инвестиция программасына төзәтмә кертү турында гариза (әлеге регламентка 2 нче кушымта);

2) җирле үзидарә органы һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан килештерелгән, техник бирем һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә эшчәнлек башкара торган оешмаларның инвестиция һәм производство программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карары белән расланган Кайнар, салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыра торган оешмаларның инвестиция программаларын эшләү, килештерү, раслау һәм үзгәртү кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 10 пунктының тиешле таләпләре нигезендә эшләнгән инвестиция программасы проекты;

3) инвестиция программасы проектына каршылыклар беркетмәсе (булган очракта);

4) төзелгән концессия килешүе күчермәсе (объекты булып үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызу системасы торган

концессия килешүе нигезендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган җайга салынулы оешма өчен);

5) су белән тәэмин итү һәм су агызу схемасының күчермәсе һәм су белән тәэмин итү һәм су агызу схемасын раслый торган документның күчермәсе.

2.6.2. Гаризаны ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле зат тарафыннан рәсмиләштергән очракта, паспорт (шәхесне таныклый торган башка документ), нотариаль таныкланган ышаныч кәгазе яки законнар нигезендә нотариаль таныкланган ышаныч кәгазенә тигезләштерелә торган ышаныч кәгазе күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.3. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылырга яисә почта юлламасы итеп кулга тапшыру турында белдерү белән җибәрелергә мөмкин.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә туры китереп имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендә Республика порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гариза Республика порталы аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең гади электрон имзасы белән имзалана.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик багланышларын тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең электрон документ рәвешендәге (электрон документ үрнәге) ышаныч кәгазе мондый документларны ясауга һәм имзалауга вәкаләтле булган затларның, шул исәптән нотариусның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныклана.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

Гаризага теркәп тапшырыла торган документларның күчермәләре нотариаль расланырга мөмкин. Нотариаль таныкланган күчермәләр булмаганда, тигез дәрәҗәдә түбәндәгеләр кабул ителергә тиеш:

дәреслеге җитәкченең яки моңа вәкаләт бирелгән вазыйфаи затның имзасы һәм оешманың мөһере (булган очракта) белән таныкланган документларның күчермәләре;

документның төп нөсхәсен күрсәтү шарты белән, таныкланмаган күчермәләр. Шул ук вакытта документның күчермәсе документларны кабул итүче зат тарафыннан төп нөсхәсе белән чагыштырыла.

2.6.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар

Министрлык тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) соратып алына:

Кагыйдәләр нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан расланган инвестиция программасын эшләүгә техник бирем күчермәсе;

инвестиция программасы проектын үз территориясендә инвестиция программасы чаралары гамәлгә ашырыла торган җирлекнең (шәһәр округының) җирле үзидарә органы белән килештерүне раслый торган документ;

инвестиция программасы проектын Дәүләт комитеты белән килештерүне раслый торган документ.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга мөмкин булган документларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә дә тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән Мөрәҗәгать итүчеләр категорияләренә керми торган затның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган кирәкле документларның тулы булмаган комплект белән тапшырылуы;

3) 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланган имзаланмаган (таныкланмаган) гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) тапшырылуы (гаризаны электрон рәвештә тапшырган очракта).

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) инвестиция программасының Кагыйдәләрнең 10 пунктында күрсәтелгән

инвестиция программасы эчтәлегенә карата таләпләргә туры килмәве;

2) инвестиция программасының техник биремгә туры килмәве;

3) абонентлар өчен җайга салына торган оешма тарифларының мөмкинлекле булмавы, мондый баш тарту концессия килешүе объектын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү буенча концессионер йөкләмәләрен үтәмәүгә китереп чыгарган очрактан тыш;

4) инвестиция программасы проектында күрсәтелгән инвестиция программасы чараларын гамәлгә ашыру бәясенең Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган капиталь төзелеш объектларын һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын төзүнең төрле төрләрен төзүнең яшерелгән нормативлары буенча билгеләнгән күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру бәясеннән артып китүе (2022 һәм 2023 елларда әлеге абзац таләбе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы, җылылык, газ, су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәләрендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләрен билгеләү максатларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 20 маендагы 912 номерлы карары нигезендә кулланылмый);

5) раслана торган инвестиция программасына концессия килешүе нигезендә кертелгән чараларны гамәлгә ашыру һәм концессия килешүе үз көченә кергәннән соң расланган һәм концессия килешүенә кертелгән чараларны, тоташтырган (техник ялгаган) өчен түләү хисабына финанслана торган чаралардан тыш, үз эченә алган инвестиция программасына концессия килешүе нигезендә кертелгән чараларны гамәлгә ашыру чыгымнары суммасының, концессия килешүе объектын булдыру һәм (яки) үзгәртеп кору һәм (яки) модернизацияләү, әхлакый тузган һәм физик таушалган, концедент тарафыннан концессия килешүе буенча концессионерга тапшырыла торган башка мөлкәтне тагын да җитештерелешлерәк, мондый мөлкәтнең характеристикалары һәм файдалану үзлекләре башкача яхшырак булган яңа мөлкәткә алмаштыру (концессия килешүе нигезендә концессионер гамәлгә ашырырга планлаштырган) чыгымнарының чик суммасының артып китүе.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, теркәү гарызнамә һәм документлар кергән көнне башкарыла. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

2.11.2. Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә озата йөри торган этне кертү;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документлар кабул ителә, бирелә торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

гаризаны һәм документларны электрон документлар рәвешендә Республика порталы аша тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталында шәхси кабинет аша дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон рәвештә алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;

3) Министрлык белгечләренең әлеге регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итү саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык хезмәткәрләре белән үзара хезмәттәшлек итүе түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

барлык кирәкле документлар белән гариза тапшырылганда, – бер тапкыр;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алган очракта, бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә үзара бәйләнешкә керү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталында шәхси кабинеттан, Министрлыкта алынырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелергә мөмкин.

2.14.3. Дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелми.

2.14.4. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм реестр язуларында бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары

Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерыла.

3.2. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча юллау административ процедурасын тасвирлау

Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча җибәрү гамәлгә ашырылмый.

3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза тутыру өлешендә дә;

2) гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү;

3) гаризаны карау һәм тапшырылган документларның комплектлы булу-булмавын тикшерү;

4) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

5) мөрәҗәгать итүче тапшырган исәпләмәләрне һәм материалларны анализлау;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

7) техник хатаны төзәтү.

3.4. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә дә

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) Министрлыкның рәсми сайты, Республика порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече шәхсән, телефон, электрон почта аша, язмача һәм (яки) хат аша мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә дә, шулай ук, кирәк булганда, гариза рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның һәм тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләрдә консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.5. Гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү

3.5.1. Теркәлгән документлар пакеты белән гаризаны кабул итү һәм теркәү административ процедурасын башлап җибәрү нигезе булып мөрәҗәгать итүченең шәхсән, ышанычлы заты аша, почта буенча, электрон почта буенча Министрлыкка, Республика порталы аша әлеге регламентның 2.6.1 пункты нигезендә документларны (документларның күчермәләрен) теркәп, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыруы тора.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм документлар.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Республика порталы аша электрон формада кабул итү

3.5.2.1. Гаризаны электрон формада тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизация уза;
электрон гариза формасын ача;
дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;
электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);
электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);
хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);
тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);
электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.3 пункты таләпләре нигезендә имзалана;
электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.
Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.
Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.
3.5.3. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша, почта буенча, электрон почта буенча Министрлыкка мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны кабул итү
3.5.3.1. Министрлыкта урнашкан корреспонденцияне теркәү өчен җаваплы булган, Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенең вазыйфаи заты (алга таба – документлар теркәү өчен җаваплы вазыйфаи зат) Министрлыкта билгеләнгән эш тәртибендә почта аша, Министрлыкның рәсми сайтыннан файдаланып яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы (алга таба – электрон документ әйләнеше) аша электрон чыганакта алынган гаризаны терки, шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшырылган гаризаның ике нөсхәсенә дә керә торган номер беркетә, шуның берсен мөрәҗәгать итүчегә бирә.
Документларны теркәү өчен җаваплы вазыйфаи зат Министрлыкта билгеләнгән эшчәнлек башкару тәртибендә гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны (документларның күчермәләрен) электрон формада электрон документ әйләнеше системасы аша министрның инвестиция программаларын раслау мәсьәләләрен тикшерүдә тотучы урынбасарына яки аны алмаштыручы затка (алга таба – министр урынбасары) җибәрә.
Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.
Процедураның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: теркәлгән гариза һәм документлар.

3.6. Гаризаны карау һәм тапшырылган документларның комплектлы булу-булмавын тикшерү

3.6.1. Министр урынбасары Министрлыкта эш башкару күрсәтмәсендә каралган тәртиптә гариза һәм аңа теркәлә торган документларны (документларның күчермәләрен) электрон документ әйләнеше системасы аша бүлеккә һәм коммуналь хуҗалык һәм оператив эш бүлегенә җибәрә.

Бүлек җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган структур бүлекчә вазифаи затын (алга таба – бүлекнең вазыйфаи затын) (резолюция рәвешендә) билгели.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документлар Министрлыкта теркәлгән көннән соң өч календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бүлекнең вазыйфаи затына юлланган гариза һәм документлар.

3.6.2. Бүлекнең вазыйфаи заты документларның әлеге регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән исемлеккә туры килү-килмәве буенча һәм документларның дөрес рәсмиләштерелгән булу-булмавын: комплектлылыгын, күрсәтелгән кушымталары булуын, таныклый торган реквизитлары (имза, штамп, теркәлү номеры, фамилиясе һәм алучының телефон номеры) булуын, гариза тутыруның төгәл булу-булмавын тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар әзерли.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре мондый документларга белдерелә торган таләпләрне бозуга бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту нигезләрендә тапшырылмаган, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләре булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматның, белешмәнең) атамасы турында мәгълүмат күрсәтелергә тиеш), килештерү өчен билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын Министрлыкта эшчәнлек башкару тәртибендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, бүлекнең вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүче тапшырган исәпләмәләрне һәм материалларны анализлауга керешә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза карауга алынган көннән соң өч календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: карауга кабул ителгән гариза яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар.

3.7. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.7.1. Административ процедураны үтәү өчен мөрәҗәгать итүчедән бүлекнең вазыйфаи затның документларны кабул итүе нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып Бүлек белгече тора.

3.7.2. Бүлек белгече, әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) җибәрә.

Әлеге пунктта белән билгеләнә торган процедуралар гариза карау өчен кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларны нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларга җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.7.3. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында карар) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр), яисә баш тарту турында ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка юлланган карар.

3.8. Мөрәҗәгать итүче тапшырган исәпләмәләрне һәм материалларны анализлау

3.8.1. Әлеге Регламентның 2.6.1 пункты таләпләре нигезендә гаризага теркәлә торган документларның тулы исемлеге булган очракта, бүлекнең вазыйфаи заты түбәндәгеләрне тикшерә башлый:

тапшырылган документлардагы белешмәләрнең дөрес булуын;

тапшырылган документлар рәвешенең һәм эчтәлегенең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен;

инвестиция программасы чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләменең Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган җитештерү өчен билгеләнмәгән һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары өчен эреләндерелгән смета нормативларына (алга таба – эреләндерелгән смета нормативлары) туры килүен, – инвестиция программасы чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләменең эреләндерелгән смета нормативларына туры килүен тикшерү турында «Татарстан Республикасының Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесенә рәсми гариза җибәрү юлы белән.

3.8.2. Коммуналь хуҗалык бүлеге җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән коммуналь хуҗалык һәм оператив эш бүлеге белгече территориясендә карала торган программа чараларын гамәлгә ашыру күздә тотылган муниципаль берәмлекне су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу схемасының инвестиция программасы чараларының туры килүен тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.6.2 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач ун календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: инвестиция программасын раслау турында карар, инвестиция программасына үзгәрешләр кертү турында яки инвестиция программасын раслаудан, инвестиция программасына үзгәрешләр кертүдән баш тарту һәм аны өстәмә эшләп бетерү өчен юллау турында карар әзерләү.

3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.9.1. Инвестиция программасын раслау турында карар, инвестиция программасына төзәтмә кертү турындагы карар кабул ителгән очракта, бүлекнең вазыйфаи заты инвестиция программасын раслау турында яки инвестиция программасына төзәтмә кертү турында Министрлык боерыгы проектын (алга таба – боерык проекты) әзерли һәм аны, килештерү өчен, бүлек җитәкчесенә, коммуналь хуҗалык һәм оператив эш бүлеге җитәкчесенә, Торак-коммуналь хуҗалык идарәсе җитәкчесенә, юридик бүлек җитәкчесенә, эшләр идарәчесенә, министр урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.7 пунктында каралган процедура төгәлләнгәннән соң биш календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: боерык проекты.

3.9.2. Бүлек җитәкчесе, коммуналь хуҗалык һәм оператив эш бүлеге җитәкчесе, Торак-коммуналь хуҗалык идарәсе җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе, эшләр идарәчесе, министр урынбасары үз компетенциясе кысаларында боерык проектын имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты килештерү өчен алынган көннән соң өч календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрга имзалау өчен юнәлдерелгән, килештерелгән боерык проекты.

3.9.3. Министр боерык проектын карый, имзалый һәм документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты килештерү өчен алынган көннән соң өч календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган инвестиция программасын раслау турында яки инвестиция программасына үзгәрешләр кертү турында боерык.

3.9.4. Министрлыкның Министрлыкта боерыкларны теркәү өчен җаваплы булган документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенең вазыйфаи заты боерыкны терки һәм бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура инвестиция программасын раслау турында яки инвестиция программасына төзәтмә кертү турында боерык министр тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән, бүлеккә юлланган боерык.

3.9.5. Бүлекнең вазыйфаи заты боерыкны Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында урнаштыра, аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә

һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары актларын бастырып чыгару өчен каралган тәртиптә рәсми бастырып чыгару өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карарны теркәгәннән соң өч календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән боерык.

3.9.6. Министрлык тарафыннан инвестиция программасын раслаудан баш тарту яки инвестиция программасына төзәтмә кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә һәм аны әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләрдә өстәмә эшләп бетерү өчен җибәргән очракта, бүлекнең вазыйфаи заты инвестиция программасын раслаудан баш тарту яисә инвестиция программасына төзәтмә кертүдән баш тарту турында язма карар әзерли һәм аны, имзалау өчен, баштa бүлек җитәкчесе, коммуналь хуҗалык һәм оператив эш бүлеге җитәкчесе, Торак-коммуналь хуҗалык идарәсе җитәкчесе, министр урынбасары белән килештереп, министрга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.8 пунктында каралган процедура тәгәлләнгәннән соң биш календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: инвестиция программасын раслаудан баш тарту яки инвестиция программасына төзәтмә кертүдән баш тарту һәм аны өстәмә эшләп бетерү кирәклеге турында язмача карар.

3.9.7. Министр инвестиция программасын раслаудан баш тарту яки инвестиция программасына төзәтмә кертүдән баш тарту һәм аны өстәмә эшләп бетерү кирәклеге турында язма карарны карый, имзалый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура язма белдерүне алганнан соң өч календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: инвестиция программасын раслаудан баш тарту яки инвестиция программасына төзәтмә кертүдән баш тарту һәм аны өстәмә эшләп бетерү кирәклеге турында язмача карар.

3.9.8. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенең Министрлыктан җибәрелә торган корреспонденцияне теркәү өчен җаваплы вазыйфаи заты инвестиция программасын раслаудан баш тарту яки инвестиция программасына төзәтмә кертүдән баш тарту һәм аны өстәмә эшләп бетерү кирәклеге турында язма карарны терки һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура язма белдерүне алганнан соң өч календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: инвестиция программасын раслаудан баш тарту яки инвестиция программасына төзәтмә кертүдән баш тарту һәм аны өстәмә эшләп бетерү кирәклеге турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән язмача карар.

3.9.9. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка өстәмә эшләп бетерелгән инвестиция программасын Кагыйдәләрнең 22 пунктында каралган срокларда тапшыра.

Өстәмә эшләп бетерелгән инвестиция программасы әлеге Регламентның 3.5-3.7 пунктларында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

3.9.10. Инвестиция программасын раслау турында карар яки инвестиция программасын раслаудан баш тарту турында карар кабул итү рәвешендә концессия килешүе нигезендә эшчәнлек башкара торган мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

Инвестиция программасын раслау турында карар яки инвестиция программасын раслаудан баш тарту турында карар кабул итү рәвешендә концессия килешүе нигезендә эшчәнлек башкара торган мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү әлеге Регламентның 3.5-3.8 пунктларында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

3.10. Техник хатаны төзәтү

3.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатаның булуын таныклаучы документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мәгълүматларындагы техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша, электрон почта ярдәмендә яисә Республика порталы аша җибәрелә.

3.10.2. Документларны теркәү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, терки һәм аларны бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң өч календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, бүлекнең вазыйфаи затына карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.10.3. Бүлекнең вазыйфаи заты документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.8-3.9 пунктларында каралган процедураларны башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша, Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (почта яки электрон адрес буенча җибәрелгән) җавап.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен башкаруга таләпләрне билгеләүче башка

норматив хокукый актларның үтәлешен һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе.

4.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге буенча агымдагы контрольлек тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат, Бүлек җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру тәртибе һәм аларның ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына контрольлек тәртибе һәм формалары.

4.2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Министрлыктагы вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылышына, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлешенә;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүенә.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органдагы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы

булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да, контроль тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне сыйфатлый торган нигезләмәләр.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сәбәпле министр тарафыннан кабул ителгән карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, норматив хокукый актларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматлар тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан, Республика порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында да кабул итеп алынырга мөмкин.

Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләренраслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.9. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрына

_______________________________
(инициаллар, фамилия)

Гариза

___________ елга (елларга) Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешманың инвестиция программасын раслау турында

Теркәлгән документларны карау һәм инвестиция программасын раслау турында сорыйм, түбәндәгеләр өчен:

_______________________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең тулы һәм кыска (булган очракта) атамасы)

_______________________________________________________________________.
(юридик зат, аның оешу-хокук формасы яки шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

_______________________________________________________________________.

Мөрәҗәгать итүченең почта адресы ___________________________________
_______________________________________________________________________.

Мөрәҗәгать итүченең урнашу адресы: _________________________________

________________________________________________________________________.

Мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресы ______________________________
Мөрәҗәгать итүченең телефоны/факсы ___________________________________

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) _____________________________________________________________ бит.
2) _____________________________________________________________бит.

Вазыйфа Ф.И.А.(соңгысы – булган очракта)

(имза)

Мөһер урыны (булган очракта)

_______________________________________________

Юридик затларга гаризаны оешма бланкында рәсмиләштерергә киңәш ителә.

Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министрына

_______________________________
(инициаллар, фамилия)

Гариза

___________ елга (елларга) Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешманың инвестиция программасына төзәтмә кертү турында

Теркәлә торган документларны карау һәм инвестиция программасына үзгәрешләр кертү турында сорыйм: ________________________________________
(инвестиция программасының исеме)

________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының: ______________________________ боерыгы белән расланган
(документның реквизитлары)

________________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең почта адресы ___________________________________

________________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең урнашу адресы: __________________________________

________________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресы

______________________________

Мөрәҗәгать итүченең телефоны/факсы ______________________________

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) ________________________________________________, _____ биттә.
2) ________________________________________________, _____ биттә.

Вазыйфа Ф.И.А.(соңгысы – булган очракта)

(имза)

Мөһер урыны (булган очракта)

__________________________________________

Юридик затларга гаризаны оешма бланкында рәсмиләштерергә киңәш ителә.

Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрына

_______________________________

(инициаллар, фамилия)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының ________________ № _____ боерыгында җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:____________________________________________________________

Дөрес белешмәләр:_____________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган боерыкка тиешле үзгәрешләрне кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.____________________________________________________________________

2.____________________________________________________________________

3.____________________________________________________________________

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул

ителгән очракта мондый карарны:

түбәндәге адреска документ җибәрү юлы белән: ____________________;
_____________________________________________ адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

Татарстан Республикасы территориясендә кайнар су, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау һәм аларга төзәтмә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы хакимият органнары (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 231-14-02 | msagkh@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 231-15-23 | I.Nasyrov@tatar.ru |
| Торак-коммуналь хуҗалык идарәсе җитәкчесе | 231-14-99 | A.Gallyamov@tatar.ru |
| Коммуналь хуҗалыкта инвестиция программалары бүлеге җитәкчесе | 231-14-06 | Roza.Muhametzanova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге җитәкчесе | 264-76-02 | Fail.Salihov@tatar.ru |